ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАЙРЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Октября, д.1Б,

с.Байряка, 423963

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ

**РАЙОНЫ БӘЙРӘКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Октябрь урамы, 1Б йорт,

Бәйрәкә авылы, 423963

Тел.:(85593) 6-23-33, факс:6-25-28, e-mail: Bay.Utz@tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 13** **04 август 2015 ел**

Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге
башкарма комитетында муниципаль хезмәткәр, аның
ире (хатыны) һәм балигъ булмаган балалары чыгымнарының
аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору тәртибенә
үзгәрешләр кертү турында

2014 елның 22 декабрендәге «Россия Федерациясенең аерым закон актларына коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча үзгәрешләр кертү турында»гы 431-ФЗ санлы Федераль законны кабул итүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 23 мартындагы «Татарстан Республикасы Президентының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча аерым указларына үзгәрешләр кертү турында»гы ПУ-308 санлы Указын гамәлгә ашыру максатларында Бәйрәкә авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Ютазы муниципаль районының Бәйрәкә авыл җирлеге башкарма комитетының «Муниципаль хезмәткәр, аның хатыны (хатыны) һәм балигъ булмаган балалары чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору тәртибе»нә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктның беренче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән затларның чыгымнарын тикшереп торуны гамәлгә ашыру турында карар кабул итү өчен нигез булып түбәндәгеләр тора: белешмәләр тапшыру елыннан алдагы календарь ел эчендә зат, аның хатыны (ире) һәм (яисә) балигъ булмаган балалары тарафыннан җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларында катнашу өлешләре) сатып алу буенча алыш-биреш башкарылган, әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артыграк суммага төзелгән.».

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендында игълан итәргә һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында http://jutaza.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

Бәйрәкә авыл җирлеге башкарма
комитеты вазыйфаларын башкаручы Р.С.Фәтхиев